**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТРОИЦКО-УРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422657, РТ , Рыбно-Слободский район
с.Троицкий Урай
ул. Школьная, дом 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТРОЙ-УРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422657, ТР,Балык Бистәсе районы,
Трой-Урай авылы
Мәктәп урамы, 4 нче йорт

Тел.: (84361) 24320, факс: (84361)24320, e-mail: Tur.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2019 .Троицкий Урай ав. №5

**“2019 елның язгы-җәйге чорында Троицкий Урай авыл җирлегенең су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм үлемен булдырмау чаралары турында”**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий Урай авыл җирлеге территориясендә 2019 елның апреленнән 2019 елның ноябренә кадәрге чорда су объектларында кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында, “РФ дә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы РФ Законы, Татарстан Республику Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең Тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында” 256 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 15 апреленнән 15 ноябренә кадәр АҖ сулыкларында иминлек (куркынычсызлы смотры үткәрергә.
2. Боз эрү һәм боз китү вакытында автотранспорт чараларының бозга санкцияләнмәгән керү урыннарын ябарга.
3. Һәвәскәр балыкчылар бозга күпләп керә торган урыннарда кисәтү аншлаглары куярга (авыл мәдәният йорты янында ярда, мәктәп, Люткин, Совет, Гагарин урамнары азагында).
4. Гаммәви мәгълүмат чаралары белән эшне активлаштырырга , мәктәп укучылары һәм авыл халкы белән хәтәр чорда бозга чыгуны булдырмау буенча әңгәмәләр үткәрергә.
5. Халыкка суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында хәбәр итәргә, махсус җиһазландырылган пляжларда гына коенырга кирәклеге турында кисәтергә.
6. Кешеләр күпләп ял итә һәм су коена торган хәтәр урыннарда “Коену тыела” дигән белдерүләр урнаштырырга.
7. Кешеләрнең исерек хәлдә коенуларына юл куймау буенча халык белән телдән әңгәмәләр үткәрергә.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Троицкий Урай  авыл җирлеге
Башлыгы вазифаларын башкаручы Р.Х.Сафин